# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегендә 2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2022 елның 18 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Ләке торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**Карар**:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге территориясендә, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияле һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Ләке торак пунктында зират территориясен ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);
- Ләке торак пунктында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Ләке торак пунктындагы урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы лампалар сатып алу һәм урнаштыру);
- Ләке торак пунктында махсуслаштырылган МТЗ-82 техникасы өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу;
- МТЗ 82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу;
- Ләке торак пунктында җәйге чорда (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) территорияне һәм юл яны полосаларын чаптыру;
- Ләке авыл җирлегендә “Питрау” бәйрәменә приз һәм бүләкләр сатып алу;
- Ләке торак пунктында өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлары сатып алу.

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы _ _ _ _ _ _ Шәрипова Л.И.